# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Совет Социалистик Республикасы
Конституциясенә /Төп Законына/ үзгәрешләр
турында**

Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы

КАРАР БИРӘ:

I. Татарстан ССР Конституциясенә /Төп Законына/ түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 158 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"158 статья. Татарстан Совет Социалистик Республикасының Дәүләт флагы аркылы сызыклар төшкән турыпочмаклы материядән гыйбарәт: өске өлеше - яшел төстә, уртасы - ак һәм аскы өлеше кызыл төстә. Флагның киңлеге белән озынлыгы 1:2 нисбәтендә.

II. Түбәндәге документларның көче югалган дип санарга:

"Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт флагы турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан ССР Югары Советы Президиумының 1956 елның 13 февралендәге Әмере;

"Татарстан Совет Социалистик Республикасы дәүләт флагының график тасвирламасын раслау турында" Татарстан ССР Югары Советы Президиумы Әмерен раслау хакында" Татарстан ССРның 1978 елның 22 декабрендәге Законы;

"Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт флагы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү ту-

рында" Татарстан ССР Югары Советы Президиумы әмерен раслау хакында" Татарстан ССРның I98I елның 2 июнендәге Законы.

III. Әлеге Закон кабул ителгән мизгелдән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан,
I99I елның 29 ноябре
№ I322-XII